ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д.13, д. Средняя
Корса, Арский муниципальный район,
422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 13 нче йорт, Урта Курса
авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«19» август 2025 ел** **№ 29**

**Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 25 гыйнварындагы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларның туплану урыннарын билгеләү турында” 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 14 мартындагы “Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында Нигезләмәне раслау хакында” 300 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 25 гыйнварындагы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларның туплану урыннарын билгеләү турында” 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 һәм 5 пунктларны 5 һәм 6 пунктлар дип санарга;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урынының (урыннарының) урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Вафина